ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 елның «09» июненнән № 242

**«Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын уздыру турында»**

2016 елда «Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» республика конкурсын уздыру турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 1 июнендәге 391 номерлы карары нигезендә, **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын үткәрергә.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсы турында кушымта итеп бирелгән нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

3. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын уздыру буенча конкурс комиссиясе составын расларга (2 нче кушымта).

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары итеп йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «09» июнендәге
242 номерлы карарга
1 нче кушымта

**«Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсы турында нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә «Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын (алга таба - Конкурс) үткәрү тәртибен билгели.

2. Конкурсны оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты гамәлгә ашыра.

3. Конкурсны уздыру максатлары:

территориаль иҗтимагый үзидарә эшенең нәтиҗәлелеген арттыру;

Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүдә халыкның эшлекле һәм социаль активлыгын үстерү һәм стимуллаштыру.

4. Конкурсның бурычлары:

җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен яшәү урыны буенча гражданнарның үзоешуында иң яхшы нәтиҗәләргә ирешкән территориаль иҗтимагый үзидарәләрне ачыклау;

территориаль иҗтимагый үзидарәдә актив катнашучы район халкын бүләкләү;

территориаль иҗтимагый үзидарәнең уңай тәҗрибәсен ачыклау һәм тарату.

II. Конкурста катнашу шартлары

1.Конкурста катнашучылар булып Яңа Чишмә муниципаль районының территориаль иҗтимагый үзидарә органнары (алга таба - Катнашучылар) тора, алар конкурста катнашуга гаризалар (алга таба - гаризалар) бирә.

## III. Конкурс үткәрү

2. Конкурс бер этапта уздырыла.

3. Катнашу өчен гаризаларны конкурс комиссиясе кабул итә һәм теркәп бара. Гаризалар кабул итүне тәгәлләү срогы әлеге Нигезләмәнең IV бүлекнең 5 пунктында билгеләнгән.

4. Конкурс комиссиясе Конкурска тәкъдим ителгән гаризаларга эксперт бәясен гамәлгә ашыра һәм җиңүчеләрне билгели.

5. Конкурска бирелгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтмый.

## IV. Гаризалар әзерләү һәм тәкъдим итү

1. Конкурста катнашучылар гариза әзерлиләр һәм аны конкурс комиссиясенә тапшыралар. Гаризаны почта аша җибәрергә, шәхсән яисә курьер аша бирергә мөмкин. Теләсә нинди формада конкурска гаризаны теркәү датасы конкурс комиссиясенә гариза кергән дата буенча билгеләнәчәк. Конкурсны оештыручылар почта яки курьер хезмәте эше өчен җаваплылык тотмый.

2. Гариза составына түбәндәге документлар керергә тиеш:

территориаль иҗтимагый үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан таныкланган конкурста катнашуга гариза;

территориаль иҗтимагый үзидарә органының уставы яисә җайга сала торган башка документы күчермәсе.

3. Гариза шрифт күләме 12 дән дә ким булмаган А4 (1 нөсхә) форматында кәгазь чыганакта һәм теләсә нинди электрон чыганакчта Microsoft World форматында бирелә. Калган барлык документлар кәгазьдә генә бирелә.

Гаризаны тутырганда барлык белешмәләр дә соңгы ел өчен күрсәтелә.

4. Конкурска гаризалар әзерләүгә һәм бирүгә бәйле чыгымнарны конкурста катнашучылар күтәрә.

5. Заявкалар 2016 елның 8 июненнән 22 июненә кадәр кабул ителә.

6. Конкурсның башлануы турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән сроктан соң бирелгән яисә әлеге Нигезләмәнең IV бүлекнең 3 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килми торган гаризалар Конкурста катнашуга кабул ителми.

## V. Конкурс комиссиясе

1. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү максатларында кимендә 5 әгъзадан торган конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясенең персональ составы әлеге Нигезләмә белән бергә раслана.

2. Конкурс комиссиясе әлеге Нигезләмә нигезендә эш итә. Конкурс комиссиясе утырышларын конкурс комиссиясе рәисе, ул булмаган очракта - рәис урынбасары алып бара.

3. Конкурс комиссиясе түбәндәге функцияләрне башкара:

катнашучыларның гаризаларын җыюны оештыралар;

катнашуга дәгъва итүчеләрне конкурска кертү (кертүдән баш тарту) турында карар кабул итә;

кергән заявкаларны әлеге Нигезләмәнең V бүлекнең 6 пунктында күрсәтелгән критерийлар нигезендә бәяли;

конкурста җиңүчеләрне билгели.

Конкурс комиссиясе әгъзалары утырышларда алмаштыру хокукыннан башка шәхсән катнашалар.

4. Катнашуга дәгъвачыларны Конкурска кертү турындагы карар документларны кабул итү тәмамланганнан соң 3 эш көне эчендә кабул ителә.

5. Катнашуга дәгъвачыларны Конкурска кертү турында карар кабул ителгәннән соң конкурс комиссиясе гаризаларны карый, бәяләүне гамәлгә ашыра һәм конкурста җиңүчеләрне билгели.

6. Конкурс комиссиясе гаризаны ун баллы шкала буенча түбәндәге критерийлар нигезендә бәяли:

соңгы елда халыкны карарлар кабул итү процессына җәлеп итү буенча территориаль иҗтимагый үзидарә эше, шул исәптән үткәрелгән җыелышлар (советлар, конференцияләр, территориаль иҗтимагый үзидарә органнары утырышлары) һәм карала торган мәсьәләләр;

территориаль иҗтимагый үзидарә территориясендә яшәүче гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау, соңгы елда мөрәҗәгатьләр буенча эш нәтиҗәләре;

хакимият органнарына территориаль иҗтимагый үзидарә тәкъдимнәрен әзерләү һәм әлеге тәкъдимнәр буенча соңгы елда эш нәтиҗәләре;

соңгы елда төрле дәрәҗәдәге территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең хакимият органнары белән үзара хезмәттәшлеге һәм киңәшмә органнары (комиссияләр, советлар һ.б. эшендә катнашу;

халыкның социаль якланмаган төркемнәренә (күпбалалы һәм аз керемле гаиләләр, инвалидлар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, соңгы елда территориаль иҗтимагый үзидарә территориясендә яшәүче ялгыз өлкән гражданнар) ярдәм күрсәтү эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

территориаль иҗтимагый үзидарә гамәлгә ашырыла торган территориядә яшәүчеләрне территорияне төзекләндерү һәм яшелләндерүдә катнашуга җәлеп итү, соңгы елда өмәләр уздыру;

соңгы елда гомуми файдалану урыннарыннан файдалануга җәмәгать контролен тәэмин итү (җәмәгать контроле рейдлары үткәрү) максатында территориаль иҗтимагый үзидарә чараларын гамәлгә ашыру;

территориаль иҗтимагый үзидарә эшчәнлеген гамәлгә ашыруга, соңгы елда бюджеттан тыш финанслауга җәлеп ителгән суммалар;

соңгы елда массакүләм мәгълүмат чараларында территориаль иҗтимагый үзидарәләрнең эшчәнлеге һәм казанышлары турында мәгълүматны яктырту.

7. Конкурс комиссиясе карарлары, шул исәптән Конкурс нәтиҗәләре турындагы карарлар, утырышта катнашучы конкурс комиссиясе әгъзаларыннан күпчелек тавыш белән кабул ителә, конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан имзалана торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Беркетмәләрдә конкурс комиссиясе әгъзаларының аерым фикере (булса) күрсәтелә.

8. Әгәр конкурс комиссиясе утырышында аның әгъзаларының гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, Конкурс комиссиясе әлеге Нигезләмәдә каралган функцияләрне башкарырга хокуклы. Конкурс комиссиясе әгъзаларына конкурс комиссиясе утырышын уздыру урыны, датасы һәм вакыты турында 3 календарь көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителергә тиеш. Конкурсның муниципаль этабында утырышны уздыру датасы турында комиссия әгъзаларына хәбәр итү өчен конкурс комиссиясе секретаре җаваплы.

## VI. Конкурсны уздыру йомгаклары

1. Конкурс комиссиясе карары нигезендә җиңүче билгеләнә, ул II республика этабына җибәрелә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2016 елның «09» июнендәге
242 номерлы карарга
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында елның иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсын уздыру буенча конкурс комиссиясе составы**

**Конкурс комиссиясе рәисе:**

Фасахов Р.Р. - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

**Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары:**

Габетдинов Р.Х. - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары

**Конкурс комиссиясе секретаре:**

Алукаев Р.Р. - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык бүлегенең әйдәп баручы белгече

**Конкурс комиссиясе әгъзалары:**

Галимов Х.Х. - «Кристалл» идарәче компаниясе» ҖЧҖ директоры (килешү буенча)

Левашин Д.Ю. - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ башлыгы

Маланчева Т.Н. - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре (килешү буенча)

Роменский И.А. - «Яңа Чишмә МПП ЖКХ» ҖЧҖ директоры (килешү буенча)